КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1761

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибен раслау хакында» 2019 ел, 3 март, 248 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибен раслау хакында» 2019 ел, 3 март, 248 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август, 753 нче; 2021 ел, 1 декабрь, 1158 нче; 2023 ел, 28 ноябрь, 1524 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карар 2024 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 248 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 декабрь, 1761 нче
карары редакциясендә)

Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча
Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән
максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен
штраф түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм
Татарстан Республикасы бюджетына күчерү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $71^1$ статьясындагы 6 өлешендә каралган югары белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары (бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары) буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турындагы шартнамә йөкләмәләрен үтәмәгән өчен штраф түләү механизмын, шулай ук аның күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

заказчы – республика башкарма хакимият органы, дәүләт учреждениесе, дәүләт унитар предприятиесе, дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе, устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган хуҗалык җәмгыятьләре, дәүләт корпорациясе милкендә яисә аның ышанычлы идарәсендә акцияләре булган акционерлык җәмгыятьләре;

шартнамә – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан укыту турында» 2020 елның 13 октябрендәге 1681 номерлы карары белән расланган бертип форма буенча төзелә торган максатчан укыту турында шартнамә.

3. Заказ бирүче тарафыннан гражданны максатчан укыту турындагы шартнамә нигезендә эшкә урнаштыру яисә максатчан укыту турындагы шартнамәне берьяклы тәртиптә өзү йөкләмәләре үтәлмәгән, билгеләнгән квота чикләрендә Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программасы буенча укырга кабул ителгән граждан белән максатчан укыту турында шартнамә төзүдән баш тартылган очракта, заказчы әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы икенче, өченче абзацларында билгеләнгән күләмдә штраф түли.

4. Граждан тарафыннан максатчан укыту турында шартнамәдә билгеләнгән вакыт эчендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәләре үтәлмәгән яки максат-

чан укыту турындагы килешү бер яклы тәртиптә өзелгән очракта, граждан әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы дүртенче, бишенче абзацларында билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гражданны югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада укыту өчен тотылган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары күләмендә штраф түли.

5. Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укыган гражданны укудан туктаткан очракта, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасы укудан туктату турында боерык чыгарылган көннән 10 календарь көн эчендә, сәбәпләрен күрсәтеп, укудан туктату факты турында заказчыга язма рәвештә хәбәр итә.

Заказчы ел саен, граждан эшкә урнашуның билгеләнгән срогы көненнән өч ел узганга кадәр, гражданның шартнамә нигезендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсен үтәве турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы язма рәвештә хәбәр итә.

6. Әгәр шартнамә өзелсә һәм граждан хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәләрен үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителмәсә, заказчы шартнамә өзелгәннән соң бер ай эчендә граждан тарафыннан хезмәт эшчәнлеген башкару йөкләмәләре үтәлмәве турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына язма хәбәрнамә җибәрә.

Әгәр шартнамә өзелсә һәм заказчы гражданны эшкә урнаштыру йөкләмәләрен үтәүдән азат ителмәсә, граждан шартнамә өзелгәннән соң бер ай вакыт эчендә заказчы тарафыннан эшкә урнаштыру йөкләмәләре үтәлмәү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына язма хәбәрнамә җибәрә.

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә алынган яисә тикшерү нәтиҗәсендә шартнамәнең йөкләмәләре үтәлмәү турында белешмәләр алынган очракта, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы язма рәвештә шартнамә йөкләмәсен үтәмәгән шартнамә ягына (заказчыга яисә гражданга тиешенчә) штраф түләүгә карата таләп җибәрә, анда штраф күләме, аны түләү срогы һәм «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» бюджет керемнәре администраторының шәхси счеты реквизитлары күрсәтелә.

8. Штраф күләме түбәндәге шартларга туры китереп билгеләнә:

әгәр заказчы гражданны эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәсә, штраф Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән билгеләнә торган Татарстан Республикасының югары белем бирү мәгариф оешмаларында шартнамә нигезендә граждан үзләштергән югары белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар (алга таба – норматив чыгымнар) күләмендә алына;

әгәр заказчы билгеләнгән квота чикләрендә Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программасы буенча укырга кабул ителгән граждан белән максатчан укыту турында шартнамә төзүдән баш тартса яки граждан беренче арадаш аттестация узганга кадәр максатчан уку турында килешүне бер яклы тәртиптә өзгән булса, штраф бер ел укуга

норматив чыгымнар күләмендә гражданның беренче уку елына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары күләмендә алына;

әгәр граждан шартнамә шартларында мәгариф программасын үзләштереп бетерсә һәм хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәләрен тулысынча яисә өлешчә үтәмәсә, штраф күләме норматив чыгымнар нигезендә шартнамәдә билгеләнгән хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру срогы чикләрендә эшләнмәгән вакыт өлешенә (көннәргә) пропорциональ рәвештә билгеләнә;

әгәр граждан шартнамә шартларында белем бирү программасын үзләштереп бетермәгәнгә күрә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәләрен үтәмәсә, штраф күләме федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф стандартында билгеләнгән мәгариф программасы буенча белем алу срогыннан мәгариф программасы буенча фактта уку чорын (көннәрен) тәшкил иткән өлешкә пропорциональ рәвештә билгеләнә.

9. Заказчы яисә граждан штраф түләүгә карата таләп алынган көннән алып 12 айдан да соңга калмыйча «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» бюджет керемнәре администраторының шәхси счетына акча күчерү юлы белән штраф түли, аның реквизитлары штраф түләү турындагы таләптә күрсәтелә.

10. Заказчыны яисә гражданны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урта һөнәри һәм югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турында» 2020 елның 13 октябрендәге 1681 номерлы карары белән билгеләнгән максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәүдән азат итү өчен нигезләр булганда, штраф түләү турында таләп алган заказчы яисә граждан, тиешле нигез булуын раслый торган документның (документларның) күчермәсен теркәп, тиешле нигез булу турында язма рәвештә хәбәрнамә җибәрә.

11. Штраф билгеләнгән срокта түләнмәгән очракта һәм максатчан укыту турындагы шартнамә йөкләмәләрен үтәүдән азат итү нигезләре булмаганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Россия Федерациясенең граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә суд тәртибендә штраф түләүне гамәлгә ашыра.

___________________________